**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Кече Лызи авылында урнашкан торак пунктта**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2 декабрь, 2019 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1. 2020 елда, Балтач районы Кече Лызи авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, моннан тыш, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, көндезге уку формасында укучы студентлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- чишмәне төзекләндерү, киртәләр сатып алу һәм урнаштыру; купелны төзекләндерү; чишмәгә керү юлларын ремонтлау;;

- Г. Медведев, Совет урамнары буенча юлларны норматив хәлгә китерү.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Башлык, Совет рәисе Кече Лызи авыл җирлеге
Балтач муниципаль районы С. А. Мухин